| СОВЕТ<br>Бимского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Бима авыл җирлеге<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
|---|---|
| 16.12.2020 | № 5-6 |

Бима авылы

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 елларның план чорына бюджеты турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, 52 статьяның 6 пункты, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегенең Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 елларның план чорына тәкъдим ителгән бюджет проектын карап тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 елларның план чорына бюджетын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге Карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Советының финанс-бюджет, социаль законлылык һәм хокук тәртибе даими комиссиясенә йөкләргә.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе

Э.И.Михайлов